| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.12.2025 г. Казань № под-2237/25

2025/2026 уку елында «Илһам» бөтенроссия яшь шагыйрьләр һәм язучылар конкурсын оештыру һәм үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын үтәү йөзеннән, б о е р а м:

1. 2026 елның 9 февраленнән 30 апрелено кадәр «Илһам» бөтенроссия яшь шагыйрьләр һәм язучылар конкурсын үткәрергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

2025/2026 уку елында «Илһам» бөтенроссия яшь шагыйрьләр һәм язучылар конкурсын оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәне;

2025/2026 уку елында «Илһам» бөтенроссия яшь шагыйрьләр һәм язучылар конкурсын оештыру һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын.

3. Милли мәгариф идарәсенә (А.С.Шарипова) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының мәгариф идарәләренә (бүлекләренә) һәм Россия Федерациясенең башка субъектларына җиткерергә..

4. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г.К.Имамова) Конкурсны оештыру һәм үткәрү чыгымнарын түләргә.

5. Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары муниципаль мәгариф идарә органнарына гомуми белем бирү оешмалары укучыларының конкурста катнашуын тәэмин итүне, озатучы педагогларны билгеләүне тәкъдим итәргә, аларга юлда барганда һәм конкурс үткәрү вакытында балаларның тормышы, сәламәтлеге һәм иминлеге өчен җаваплылык йөкләргә.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары М.З.Закировага йөкләргә.

Министр И.Г.Хадиуллин

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән
министрлыгының 2025
елның «_30__» _12____
номерлы боерыгы белән

2025/2026 уку елында «Илһам» бөтенроссия яшь шагыйрьләр һәм язучылар конкурсын оештыру һәм үткәрү турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2025/2026 уку елында «Илһам» бөтенроссия яшь шагыйрьләр һәм язучылар конкурсын оештыру һәм үткәрү турындагы әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Илһам» бөтенроссия яшь шагыйрьләр һәм язучылар конкурсының (алга таба – Конкурс) максатын, бурычларын, оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели. 1.2. Конкурс Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелә.

## II. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның төп максаты — татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау һәм үстерү.

2.2. Конкурсның бурычлары:

укучыларда иҗади фикерләүне һәм туган әдәбиятка кызыксынуны формалаштыру;

әдәби иҗатка сәләтле яшь талантларны ачыклау;

яшь язучыларны популярлаштыру, аларның осталыкларын үстерүгә ярдәм итү.

## III. Конкурсны оештыручылар

3.1. Конкурсның төп оештыручысы — Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3.2. Конкурсның уртак оештыручылары:

«Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы (Иҗат берлеге) (алга таба – Язучылар берлеге) (килешү буенча);

«Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесе (алга таба – К(И)ФУ) (килешү буенча).

## IV. Конкурс үткәрү этаплары

4.1. Конкурс 2 этапта үткәрелә:

I этап – читтән торып (заочный) – 2026 елның 24 февраленнән 5 мартына кадәр;

II этап – турыдан-туры катнашып (очный) – 2026 елның 16 мартыннан 25 мартына кадәр.

## V. Конкурс катнашучылары

5.1. Конкурста Россия Федерациясе гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныф укучылары үзләре иҗат иткән әсәрләре белән катнаша алалар.

5.2. Конкурс түбәндәге яшь категорияләре арасында үткәрелә:

-гомуми белем бирү оешмаларының 5-7 сыйныф укучылары;

-гомуми белем бирү оешмаларының 8-9 сыйныф укучылары;

-гомуми белем бирү оешмаларының 10-11 сыйныф укучылары.

## VI. Конкурс номинацияләре

6.1. Конкурс татар телендә түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Яшь шагыйрь» (һәр яшь категориясендә);

«Яшь прозаик» (һәр яшь категориясендә);

«Яшь журналист» (һәр яшь категориясендә);

«Яшь драматург» (8-9, 10-11 сыйныфлар);

«Яшь тәрҗемәче» (10-11 сыйныфлар).

6.2. Бер үк вакытта ике номинациядән артык катнашу рөхсәт ителми, шул очракта һәр номинация буенча аерым гариза тапшырыла.

## VII. Оештыру комитеты

7.1. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен Министрлык, шулай ук Язучылар берлеге һәм К(И)ФУ вәкилләреннән (алар белән килештереп) кимендә 11 кешедән торган Конкурсның Оештыру комитеты төзелә. Оештыру комитеты составы Министрлык боерыгы белән раслана.

7.2. Оештыру комитетның вәкаләтләренә керә:

Конкурс үткәрү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;

гаризаларны теркәү;

Конкурс жюрисын формалаштыру һәм аның эшен координацияләү;

Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының мәгариф өлкәсендә идарә итүче җирле үзидарә органнарына Конкурс үткәрү турында хәбәр итү;

турыдан-туры катнашу этабы катнашучыларының квотасын билгеләү;

Конкурс лауреатларының квотасын билгеләү;

турыдан-туры катнашу этабы үткәрү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен зоналарга бүлү (килештереп);

Гран-при иясен, җиңүчеләрне һәм Конкурс лауреатларын бүләкләү тантанасын оештыру;

башка кирәкле оештыру мәсьәләләре буенча карарлар кабул итү.

## VIII. Жюри

8.1. Конкурсның читтән торып катнашу этабындагы иҗади эшләрне, турыдан-туры катнашу этабындагы катнашучыларның чыгышларын бәяләү өчен мәдәният эшлеклеләре, Язучылар берлеге, К(И)ФУ вәкилләреннән (алар белән килештереп) 11 кешедән торган Конкурс жюрисы (алга таба – жюри) формалаштырыла һәм Министрлык боерыгы белән раслана. Жюри рәистән, аның урынбасарыннан һәм жюри әгъзаларыннан тора. Жюри рәисе жюри эшенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә

ашыра. Жюри рәисе булмаган очракта, аның функцияләрен рәис урынбасары башкара.

8.2. Жюри вәкаләтләренә керә:

Конкурсның читтән торып һәм турыдан-туры катнашу этапларында катнашучыларның иҗади эшләрен бәяләү;

иҗади эшләрне плагиатка тикшерү;

Гран-при иясен, Конкурс җиңүчеләрен һәм лауреатларын билгеләү;

жюри рәисе имзасы белән жюри беркетмәсен Министрлыкка тапшыру.

8.3. Жюри утырышлары турыдан-туры үткәрелә. Жюри утырышы, әгәр анда рәислек итүчене дә кертеп, жюри әгъзаларының гомуми саныннан кимендә 2/3 өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Жюри карарлары жюри әгъзалары тавышларының күпчелеге белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, жюри утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

## IX.Конкурс үткәрү тәртибе

9.1. Гаризалар һәм иҗади эшләр 2026 елның 9 февраленнән 20 февраленә кадәр түбәндәге электрон почталарга кабул ителә:
poets2024@mail.ru – «Яшь шагыйрь» номинациясе өчен;
iauthor2024@mail.ru – «Яшь прозаик», «Яшь драматург», «Яшь журналист», «Яшь тәрҗемәче» номинацияләре өчен.

Күрсәтелгән электрон почта адресларына юлланган хатның темасында мәҗбүри рәвештә номинация, фамилия, район, сыйныф күрсәтелә. Мәсәлән, Яшь шагыйрь_Сабиров_Әгерҗе_5.

Тапшырыла торган материаллар:

- әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә гариза;
- иҗади эш;
- әлеге Нигезләмәнең 9.2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларның сканерланган күчермәләре.

Әлеге Нигезләмәнең 9.1 пунктында күрсәтелгән срогыннан соң тапшырылган гаризалар кабул ителми.

9.2. Конкурсның балигъ булмаган катнашучысының ата-аналары (законлы вәкилләре) әлеге Нигезләмә белән танышуны язма рәвештә раслыйлар һәм Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә балигъ булмаган баланың шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә һәм таратуга язма рәвештә ризалык бирәләр, шулай ук катнашучылар турында мәгълүматларны күрсәтеп, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында Конкурс нәтиҗәләрен бастыруга ризалык бирәләр.

9.3. Иҗади эшне рәсмиләштерү таләпләре: Word документы, A4 форматы, Times New Roman шрифты, 14 кегль, 1,5 интервал, читтән 2 см калдырып язылырга тиеш.

9.4. Иҗади эшләр татар телендә кабул ителә.

9.5. Республика һәм бөтенроссия дәрәҗәсендәге башка әдәби конкурсларда катнашкан иҗади эшләр Конкурска кабул ителми.

9.6. Гаризалар Оргкомитет тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 9.1 пунктында күрсәтелгән документлар килгән көнне теркәлә.

9.7. Әлеге Нигезләмәнең 9.3 һәм 9.4 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килми торган иҗади эшләр Конкурска кабул ителми.

9.8. Укучыга Конкурста катнашу өчен рөхсәт бирелмәү турында анкетада күрсәтелгән электрон адрес буенча әлеге Нигезләмәнең 9.1 пунктында күрсәтелгән документлар алынган көннән өч эш көне эчендә хәбәр ителә.

9.9. Конкурска кертелмәгән гаризалар, кимчелекләр бетерелгәннән соң, әлеге Нигезләмәнең 9.1 пунктында күрсәтелгән вакыт эчендә кабат тапшырыла ала.

9.10. Конкурсның читтән торып катнашу этабы - 2026 елның 24 февраленнән 5 мартына кадәр. Бу этапта жюри әгъзалары тарафыннан Конкурс катнашучыларының иҗади эшләрен бәяләү уза.

9.11. Конкурсның читтән торып катнашу этабының иҗади эшләрен бәяләү критерийлары:

| № п/п | Критерийлар | Критерийгә туры килү дәрәҗәсе |
|---|---|---|
| 1. | Иҗади эшнең жанрга туры килүе | туры килә - 2 балл<br>туры килми - 0 балл |
| 2. | Иҗади эш темасын ачу | туры килә - 2 балл<br>туры килми - 0 балл |
| 3. | Мәгънә тулылыгы | туры килә - 2 балл<br>туры килми - 0 балл |
| 4. | Фикер оригинальлеге | туры килә - 2 балл<br>туры килми - 0 балл |
| 5. | Грамматик хаталарның булмавы | туры килә - 2 балл<br>туры килми - 0 балл |
| 6. | Хыял көче һәм иҗади якын килү | туры килә - 2 балл<br>туры килми - 0 балл |

9.12. Баллар кушыла. Максималь балл саны – 12.

Бәяләү нәтиҗәләре буенча жюри әгъзалары жюри рәисенә шәхси беркетмәләр һәм алар нигезендә төзелгән әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән һәр категория буенча катнашучыларның суммар балл саны кимү тәртибендә ранжирланган исемлеген тапшыралар.

9.13. Конкурсның турыдан-туры этабында читтән торып катнашу этабының нәтиҗәләре буенча ранжирланган исемлектә әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында билгеләнгән һәр яшь категориясе буенча, Оргкомитет тарафыннан билгеләнгән квота нигезендә позиция алган катнашучылар була.

9.14. Турыдан-туры этапта катнашучылар, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы, Россия Федерациясенең башка субъектларының мәгариф бүлекләренә (идарәләренә) электрон почта аша 2026 елның 12 мартына кадәр җиткерелә.

9.15. Конкурсның турыдан-туры этабы – 2026 елның 16 мартыннан 25 мартына кадәр. Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен турыдан-туры этап Оргкомитет тарафыннан зоналарга бүленү буенча муниципаль берәмлекләрдә уздырыла. Татарстан Республикасыннан булган катнашучылар өчен катнашу форматы – Конкурс катнашучысының үз иҗади эше белән чыгыш ясавы. Жюри катнашучыларның чыгышларын бәяли һәм балларны шәхси беркетмәләргә теркәп бара.

9.16. Турыдан-туры этапны бәяләү критерийлары:

| № п/п | Критерийлар | Критерийга туры килү дәрәҗәсе |
|---|---|---|
| 1. | Иҗади эш темасын ачу | туры килә - 2 балл<br>туры килми - 0 балл |
| 2. | Иҗади эш темасын ачу | туры килә - 2 балл<br>туры килми - 0 балл |
| 3. | Фикерләрне грамоталы бәян итү | туры килә - 2 балл<br>туры килми - 0 балл |
| 4. | Иҗади эшнең эмоциональ тәэсир итү тирәнл | туры килә - 2 балл<br>туры килми - 0 балл |
| 5. | Фантазия һәм иҗади якын килү | туры килә - 2 балл<br>туры килми - 0 балл |
| 6. | Стилистик хаталарның булмавы | туры килә - 2 балл<br>туры килми - 0 балл |

9.17. Баллар кушыла һәм жюри әгъзалары тарафыннан шәхси беркетмәләргә кертелә. Максималь балл саны – 12.

9.18. Россия Федерациясенең башка субъектларыннан булган катнашучылар өчен: катнашучыларның иҗади эшләре автор башкаруында видеоформатта яздырыла һәм әлеге Нигезләмәнең 9.1 пунктында күрсәтелгән электрон адресларга җибәрелә. Жюри катнашучыларның чыгышларын бәяли һәм балларны шәхси беркетмәләргә теркәп бара.

9.19. Конкурсның турыдан-туры этабының барлык катнашучылары катнашучы сертификатлары ала.

## X. Конкурс йомгакларын чыгару

10.1. Турыдан-туры этапны бәяләү нәтиҗәләре буенча жюри әгъзалары жюри рәисенә шәхси беркетмәләр һәм алар нигезендә әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән һәр катнашучы категориясе буенча суммар балл саны кимү тәртибендә катнашучыларның ранжирланган исемлеген тапшыралар, анда тиешле категорияне бәяләүдә катнашкан һәр жюри әгъзасының баллары кертелә.

10.2. Конкурсның турыдан-туры этабы нәтиҗәләре буенча Гран-при иясе, I, II, III дәрәҗә җиңүчеләре һәм Конкурс лауреатлары билгеләнә.

10.3. Гран-при иясе була: «гомуми белем бирү оешмаларының 5-7 сыйныф укучылары», «гомуми белем бирү оешмаларының 8-9 сыйныф укучылары», «гомуми белем бирү оешмаларының 10-11 сыйныф укучылары» категорияләре арасыннан турыдан-туры этапның ранжирланган исемлегендә беренче позицияләрне алып, нәтиҗәлелек коэффициенты иң югары булган бер катнашучы.

Нәтиҗәлелек коэффициенты (НК) түбәндәгечә билгеләнә:

$НК = Б^{факт}/Б^{макс}$ х 100%,

монда:

НК – нәтиҗәлелек коэффициенты;;

$Б^{факт}$ – катнашучы турыдан-туры этапта факттагы җыйган баллар;

$Б^{макс}$ – турыдан-туры этап өчен мөмкин булган максималь баллар.

Ранжирланган исемлектә беренче позицияне алып торган ике яки өч конкурс катнашучысының нәтиҗәлелек коэффициенты бер үк булган очракта, Гран-при иясен билгеләү буенча карар жюри утырышында жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, жюри утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

10.4. I дәрәҗә җиңүчеләре булып әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән һәр яшь категориясе һәм номинациясе буенча ранжирланган исемлекләрдә беренче позицияләрне алып торган катнашучылар була. Ранжирланган исемлектә беренче позицияне алып торган Конкурс катнашучысының балл саны ранжирланган исемлектә аннан соң килүче катнашучыларныкы белән бер үк булган очракта, бу катнашучылар буенча карар жюри утырышында жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, жюри утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Беренче позицияне алып торган катнашучы Гран-при иясе дип танылган категориядә I дәрәҗә җиңүчесе булып ранжирланган исемлектә икенче позицияне алып торган катнашучы була.

10.5. II дәрәҗә җиңүчеләре булып һәр яшь категориясе буенча ранжирланган исемлекләрдә икенче позицияләрне алып торган катнашучылар була. Ранжирланган исемлектә икенче позицияне алып торган Конкурс катнашучысының балл саны ранжирланган исемлектә аннан соң килүче катнашучыларныкы белән бер үк булган очракта, бу катнашучылар буенча карар жюри утырышында жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, жюри утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Беренче позицияне алып торган катнашучы Гран-при иясе дип танылган категориядә II дәрәҗә җиңүчесе булып ранжирланган исемлектә өченче позицияне алып торган катнашучы була.

10.6. III дәрәҗә җиңүчеләре булып һәр яшь категориясе буенча ранжирланган исемлекләрдә өченче позицияләрне алып торган катнашучылар була. Ранжирланган исемлектә өченче позицияне алып торган Конкурс катнашучысының балл саны ранжирланган исемлектә аннан соң килүче катнашучыларныкы белән бер үк булган очракта, бу катнашучылар буенча карар жюри утырышында жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, жюри утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Беренче позицияне алып торган катнашучы Гран-при иясе дип танылган категориядә III дәрәҗә җиңүчесе булып ранжирланган исемлектә дүртенче позицияне алып торган катнашучы була.

10.7. Лауреатлар булып ранжирланган исемлекләрдә III дәрәҗә җиңүчеләреннән соң килүче позицияләрне алып торган катнашучылар була. Әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән һәр катнашучы категориясе буенча лауреатлар квотасы Оргкомитет тарафыннан билгеләнә.

10.8. Конкурсның турыдан-туры этабы беркетмәсе ранжирланган исемлек һәм Гран-при иясе, җиңүчеләр, һәм Конкурс лауреатлары исемлеге кушымтасы белән жюри утырышы үткәрелгән көнне жюридә рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм утырыш үткәрелгән көннән ике эш көне эчендә Министрлыкка тапшырыла.

Гран-при иясе, җиңүчеләр, һәм Конкурс лауреатлары исемлеге жюридә рәислек итүче беркетмәгә кул куйган көннән соң биш эш көне эчендә Министрлык боерыгы белән раслана һәм расланганнан соң җиде эш көне эчендә Министрлык сайтына урнаштырыла.

10.9. Гран-при иясе, җиңүчеләр, һәм лауреатлар Министрлык дипломнары белән бүләкләнә, кыйммәтле бүләкләр белән кызыксындырыла.

10.10. Гран-при иясе, җиңүчеләр һәм Конкурс лауреатларын бүләкләү тантаналы церемониясе Казан шәһәрендә уза. Церемонияне үткәрү урыны һәм

датасы Оргкомитет тарафыннан билгеләнә һәм катнашучыларга электрон документ әйләнеше бердәм ведомствоара системасы аша рәсми хат белән хәбәр ителә.

## XI. Элемтә өчен мәгълүмат

11.1. Оргкомитет адресы: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (Казан ш., Дзержинский ур., 3 нче йорт).

## XII. Конкурсны финанслау

12.1. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

12.2. Конкурсның теләктәшләре, дәүләт һәм иҗтимагый оешмалар, шәхси затлар җиңүчеләргә, призерларга, лауреатларга һәм Конкурсның башка катнашучыларына бүләкләр билгели ала.

2025/2026 уку елында «Илһам»
бөтенроссия яшь шагыйрьләр
һәм язучылар конкурсын
оештыру һәм үткәрү
турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

2025/2026 уку елында «Илһам» бөтенроссия яшь шагыйрьләр һәм язучылар конкурсында катнашу өчен гариза формасы *

Яшь категориясе:______________________
Номинация: ________________________________

| Муниципаль берәмлек | Катнашучының паспорт буенча рус телендә фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) | Катнашучының татар телендә фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) | Туган көне |
|---|---|---|---|
| | | | |

| Сыйныф | Устав буенча мәгариф оешмасының рус телендә тулы исеме | Устав буенча мәгариф оешмасының татар телендә тулы исеме (булган очракта) | Электрон почта адресы | Элемтә өчен мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Расланган
Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгының 2025
елның «__» _____ ________
номерлы боерыгы белән

2025/2026 уку елында «Илһам» бөтенроссия яшь шагыйрьләр һәм язучылар конкурсының оештыру комитеты составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Закирова Минзалия Заһри кызы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе |
| 2. | Шарипова Алсу Сәмигулла кызы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының (алга таба – Министрлык) милли мәгариф идарәсе башлыгы, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| 3. | Гыйззәтуллина Энҗе Хәбир кызы | Министрлыкның милли мәгариф бүлеге җитәкчесе |
| 4. | Закирҗанова Зөлфия Тәлгать кызы | Министрлыкның милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы консультанты, оештыру комитеты сәркатибе |
| 5. | Зәйдуллин Ркаил Рафаил улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы (Иҗат берлеге) рәисе (килештерү буенча) |
| 6. | Җамалетдинов Радиф Рифкать улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесенең филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры (килештерү буенча) |
| 7. | Мусина Гөлия Фәргать кызы | Министрлыкның төбәкара хезмәттәшлек секторы мөдире |